РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет Староалпаровского сельского поселения Алькеевского муниципального района

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әлки муниципаль районы
Иске Алпар авыл жирлеге
СОВЕТЫ

**Адрес: 422877, РТ, Алькеевский район,**

**с. Старое Алпарово, ул. Северная, д.29**
**тел (84346) 72553**

**Адресы:422877, РТ,Әлки районы, Иске Алпар авылы, Төньяк урамы ,29**
**Факс (84346) 72553**

**РЕШЕНИЕ** Иске Алпар авылы **КАРАР**

2025нче елның 30нчы гыйнвары 110№

2018нче елның 14нче декабрендәге
“Татарстан Республикасы
Әлки муниципаль районы
Иске Алпар авыл җирлегендә
Муниципаль хезмәт турында
Нигезләмәне раслау турында”гы
Әлки муниципаль районы
Иске Алпар авыл җирлегенең
34нче номерлы карарына үзгәрешләр
кертү турында

2023нче елның 12нче декабрендәге "Россия Федерациясе дәүләт хезмәте системасы турында "Федераль законның 12 статьясына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында"гы 594нче Федераль законының 12нче маддәсе,2024нче елның 8нче августындагы «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында»гы 232нче номерлы Федераль законы нигезендә Татарстан Республикасы Әлки районы Иске Алпар авыл җирлеге Советы КАРАР КЫЛДЫ:

1. 2018нче елның 14нче декабрендәге "Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының Иске Алпар авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында"гы 34нче номерлы( 2019нчы елның 20нче мартындагы 6 нчы номерлы карары, 2020нче елның 12нче февралендәге 4 нче номерлы карары, 2020нче елның 10нчы июнендәге 10нчы номерлы, 2021нче елның ,30 нчы июлендәге 26 нчы номерлы, 2023нче елның 9нчы февралендәге 67 нчы номерлы карары, 2024нче елның 22нче мартындагы 90нчы номерлы карары редакциясендә) карарына түбәндәге

үзгәрешләрне кертергә
4 маддәнең 4пунктында", муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратына" сүзләрен төшереп калдырырга.;

6нчы маддәнең 4нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"4.Җирле үзидарә органы җитәкчесе булган муниципаль хезмәткәр, җирле үзидарә органы җитәкчесе урынбасары, мәнфәгатьләр конфликтын бетерү максатларында, алар тиешле вазыйфаны биләгән чорда әлеге җирле үзидарә органының сайланулы профсоюз органында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен яклый алмый.";

13нче маддәне яңа редакциядә үзгәртергә:

"13нче маддә.Керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру»;

13нче маддәнең 7нче пунктында "(Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре)" сүзләрен төшереп калдырырга.;

13нче маддәнең 8 нче пунктында "(Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) " сүзләрен төшереп калдырырга.;

13нче маддәнең 10нчы пунктында "(Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) " сүзләрен төшереп калдырырга.

13нче маддәнең 11нче пунктында "(Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесе) " сүзләрен төшереп калдырырга.;

14нче маддәнең 3нче пунктындагы 5нче пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: «5) белем һәм квалификация турында документ;»

30нчы маддәнең 2нчепунктындагы 2.5нче пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә:

«2.5.муниципаль хезмәткәрләргә муниципаль хезмәткә кергәндә һәм аны узу чорында граждан тарафыннан тапшырыла торган белешмәләрне тикшерүне оештыра һәм үткәрә;»

30нчы маддәнең 2нче пунктында түбәндәге эчтәлекле 2.5.1 пунктч аөстәргә.:

«2.5.1.дәүләт сере булып торган белешмәләргә билгеләнгән рәвешне кертүне рәсмиләштерә;»

2.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әлки муниципальр айоны Искеи Алпвар авыл җирлегенең мәгълүмат тактасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам

Советы Рәисе
Иске Алпар авыл җирлеге башлыгв Р.Р.Сәлахов